КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 24 декабрь г.Казань № 1280

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2021 ел, 10 февраль, 66 нчы карары белән расланган 2021 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2021 ел, 10 февраль, 66 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 16 июль, 574 нче; 2021 ел, 8 сентябрь, 846 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2021 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.1 пунктның 18 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

1.15 пунктка түбәндәге эчтәлекле «38» пунктча өстәргә:

«38) «Казан шәһәрендә Җәмигъ мәчетен төзү» (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, Казан шәһәре);»;

2 бүлектә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Авыл хуҗалыгы:

1) «Бер тәүлеккә 144 тонна җитештерүчәнлектәге кош-корт эшкәртү предприятиесе («Челны-Бройлер» ҖЧҖ, Яр Чаллы шәһәре);

2) «Биосфера-Фиш (1 нче һәм 2 нче чират)» балык тоту комплексы» («Биосфера-Фиш» ҖЧҖ, Лаеш муниципаль районы).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин